ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя Корса, Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**«09» октябрь 2024 ел** **№ 9**

**«Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2022 елның 2 мартта 145 номерлы Арча шәһәре Башкарма комитеты карарына ярашлы рәвештә, Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. «Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 16 августындагы 14 номерлы карарын (08.11.2021 №20 үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам..

Урта Курса авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе Р. Р. Вафина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609009731

**«Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## I БҮЛЕК. Гомуми нигезләмәләр

### 1.Административ регламентны җайга салу предметы

1.1. «Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү), муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларның составын, эзлеклелеген һәм башкару срокларын, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләрен, административ регламентның үтәлешен тикшереп тору рәвешләрен, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (Арча шәһәре башкарма комитеты) (алга таба - башкарма комитет) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма комитетның вазыйфаи затларына судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү тәртибен билгели.

1.2. Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү:

1.2.1. яшел үсентеләр үсүгә бәйле төзелеш, санитар һәм башка нормаларны һәм кагыйдәләрне бозу ачыкланганда, шул исәптән төзелеш биналарына, корылмаларга капиталь һәм агымдагы ремонт ясаганда, әгәр яшел үсентеләр эшләр башкаруга комачаулый икән;

1.2.2. санитар кисүләр үткәрү (шул исәптән авария хәлендәге агачларны һәм куакларны юк итү), яшел үсентеләрне реконструкцияләү һәм яшелләндерү объектларына (паркларга, бульварларга, скверларга, урамнарга, ишегалды территорияләренә) капиталь ремонт ясау (реставрацияләү);

1.2.3. инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен, шул исәптән линия объектларын төзү (реконструкцияләү);

1.2.4. инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен, шул исәптән линия объектларын капиталь яисә агымдагы ремонтлау, инженер-техник тәэмин итү челтәрләренең һәм корылмаларының авария-торгызу эшләрен башкарудан тыш;

1.2.5. капиталь төзелеш объектлары булмаган объектларны урнаштыру;

1.2.6. инженер-геологик эзләнүләр үткәрү;

1.2.7. агачлар күләгәләгән торак һәм торак булмаган биналарда норматив яктылык режимын торгызу.

1.3. Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү Россия Федерациясе урман законнары гамәлдә булмаган җирләрдә, тимер юлларга һәм автомобиль юлларына бүленгән полосаларга кермәгән җирләрдә, яшел үсентеләрне үстерү һәм карап тоту буенча агротехник чаралар башкару өчен махсус бүленмәгән җир кишәрлекләрендә (питомниклар, оранжерея комплекслары), шулай ук территориягә карамаган зиратларда эшләр башкару өчен гамәлгә ашырыла.

1.4. «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә рөхсәтсез яшел үсентеләрне кисү, инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен һәм корылмаларны авария-торгызу эшләрен башкарудан тыш, рөхсәт ителми.

### 2. Мөрәҗәгать итүчеләр даирәсе

2.1. Мөрәҗәгать итүчеләр булып, урман утыртмалары булган территорияләрдән тыш, җир кишәрлегеннән файдалану хокукына бәйсез рәвештә, физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр буларак теркәлгәннәр, юридик затлар тора.

2.2. Әлеге административ регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен тиешле вәкаләтләргә ия затлар (алга таба - вәкил) тәкъдим итәргә мөмкин.

2.3. Мөрәҗәгать итүче исеменнән чыгыш ясаучы вәкилнең вәкаләтләре Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә белән раслана.

## 3. Мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә (алга таба - профильләү) билгеләнгән тиешле билгеләренә туры килгән дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты нигезендә хезмәт күрсәтүгә, шулай ук мөрәҗәгать итүче сорап мөрәҗәгать иткән нәтиҗәгә таләпләр

3.1. Хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) мөрәҗәгать итүчене башкарма комитетта яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - күпфункцияле үзәк) шәхсән кабул иткәндә;

2) башкарма комитет яисә күпфункцияле үзәк телефоны буенча;

3) язмача, шул исәптән электрон почта, факсимиль элемтә ярдәмендә;

4) мәгълүматны ачык һәм аңлаешлы рәвештә урнаштыру юлы белән:

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба-бердәм портал);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://www.uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба - республика порталы)

Арча шәһәре башкарма комитетының рәсми сайтында (https://www.arsk.tatarstan.ru);

5) башкарма комитетның яисә күпфункцияле үзәкнең мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән.

3.2. Мәгълүмат бирү түбәндәге мәсьәләләр буенча гамәлгә ашырыла:

хезмәт күрсәтү турында гариза бирү ысуллары;

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башкарма комитет һәм күпфункцияле үзәкләр адреслары;

башкарма комитет эше турында белешмә мәгълүмат;

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар;

хезмәт күрсәтү тәртибен һәм сроклары;

хезмәт күрсәтү турында һәм аны бирү нәтиҗәләре турында гаризаны карау барышы турында белешмәләр алу тәртибе;

хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәсьәләләр (мондый хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документлар турында мәгълүмат җиткерүне дә кертеп);

Вазыйфаи затларның алар кабул итә торган карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат алу түләүсез гамәлгә ашырыла.

3.3. Мөрәҗәгать итүче телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша),

башкарма комитетның вазыйфаи заты, консультация бирүне гамәлгә ашыручы күпфункцияле үзәк хезмәткәре, кызыксынучы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүчеләргә җентекләп һәм әдәпле (корректлы) формада хәбәр итә.

Телефоннан шалтыратуга җавап, гариза бирүче шалтыраткан органның исеме, һәм телефон шалтыравын кабул иткән орган хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта) турындагы мәгълүматтан башланырга тиеш.

Әгәр башкарма комитетның вазыйфаи заты мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алмаса, телефон шалтыравы башка вазыйфаи затка җибәрелергә (күчерелергә) яисә мөрәҗәгать иткән затка кирәкле мәгълүматны соңрак алырга мөмкин булган телефон номеры хәбәр ителергә тиеш.

Әгәр җавапны әзерләү озак вакыт таләп итсә, башкарма комитетның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгатьне язма рәвештә бәян итәргә тәкъдим итә ала.

Башкарма комитетның вазыйфаи заты хезмәтләрне күрсәтүнең стандарт процедуралары һәм шартлары кысаларыннан чыга торган һәм кабул ителә торган карарга турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясый торган мәгълүмат бирүне гамәлгә ашырырга хокуклы түгел.

Телефон буенча мәгълүмат җиткерү 10 минуттан да артмаска тиеш.

Мәгълүмат бирү гражданнарны кабул итү графигы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4. Язма мөрәҗәгать буенча хезмәт күрсәтү өчен җаваплы башкарма комитетның вазыйфаи заты әлеге Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча гражданга "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә язма рәвештә мәгълүматларны җентекләп аңлата.

3.5. Бердәм порталда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары белән расланган "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры" федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәдә каралган белешмәләр урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка мөрәҗәгать итүче нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштыру программа тәэминаты хокукына ия кеше белән түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторизацияләүне, яисә аларга шәхси белешмәләр бирүне күздә тоткан лицензия яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча да керә ала.

3.6. Рәсми сайтларда, хезмәтләр күрсәтү урыннарындагы стендларда, хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри стендларда, һәм күпфункцияле үзәктә түбәндәге белешмә урнаштырыла:

а) хезмәт күрсәтү өчен җаваплы башкарма комитетның һәм аның структур бүлекчәләренең, шулай ук күпфункцияле үзәкнең урнашкан урыны һәм эш графигы;

б) хезмәт күрсәтү өчен җаваплы башкарма комитетның белешмә телефоннары, шул исәптән автоинформаторның телефон номеры (булган очракта);

в) рәсми сайтларның адреслары, шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә башкарма комитетның электрон почтасы һәм (яисә) кире элемтә формасы.

3.7. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсендә хезмәт күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар, шул исәптән аны бирүнең "Дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә расланган административ регламенты күчермәсе урнаштырыла, алар мөрәҗәгать итүче таләбе буенча танышу өчен бирелә.

3.8. Күпфункцияле үзәк бинасындагы мәгълүмат стендларында хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштыру әлеге регламентта билгеләнгән мәгълүмат бирүгә таләпләрне исәпкә алып, "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре белән федераль башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә күпфункцияле үзәк белән башкарма комитет арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны карау барышы һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан бердәм порталдагы шәхси кабинетта, шулай ук мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта аша мөрәҗәгать иткәндә, башкарма комитетның тиешле структур бүлекчәсендә алынырга мөмкин.

## II БҮЛЕК. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### 4. Муниципаль хезмәт исеме

4.1. Муниципаль хезмәтнең исеме - "Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү" (алга таба-хезмәт күрсәтү).

### 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы (оешмасы) исеме

5.1. муниципаль хезмәтне Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә.

### 6. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы

6.1. хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү тора. Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт әлеге административ регламентның 1 нче кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелә.

6.2. әлеге административ регламентның 6.1 пунктында күрсәтелгән хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе:

а) мөрәҗәгать итүчегә вәкаләтле вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, әгәр мондый ысул яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турындагы гаризада күрсәтелгән булса, бердәм порталдагы, республика порталындагы шәхси кабинетка җибәрелә;

б) башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә кәгазьдә мөрәҗәгать итүче сайлаган хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысулы нигезендә бирелә.

### 7. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы

7.1. гариза бирүче яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гариза Арча шәһәре башкарма комитетында теркәлгән көннән алып 17 эш көненнән артмаска тиеш.

7.2. муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән исәпләнә башлый.

7.3. муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми срогына ведомствоара соратуларны җибәрү һәм аларга җавап алу срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны җибәрү срогы керә.

## 8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр

8.1. муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) "Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## 9. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

9.1. муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтүләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның һәм белешмәләрнең тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе:

9.1.1. мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле яшел үсентеләрне кисү хокукына әлеге административ регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән форма буенча рөхсәт бирү турында гаризаны, шулай ук аңа кушып бирелә торган әлеге административ регламентның 2.8 пунктындагы "б" - "г" пунктчаларында күрсәтелгән документларны үзе сайлаган түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшыра:

а) электрон формада "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы" (алга таба - бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә.

Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турында гаризаны һәм аңа беркетелә торган документларны күрсәтелгән ысул белән тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле "Дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларын бирү өчен файдаланыла торган мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы" (алга таба - ЕСИА) федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып теркәү, идентификацияләү һәм аутентификацияләү процедураларын узган электрон формада хезмәт күрсәтүләр яисә башка дәүләт мәгълүмат системалары, әгәр мондый дәүләт мәгълүмат системалары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үзара хезмәттәшлекне тәэмин итсәләр, күрсәтелгән мәгълүмат системаларында физик зат турында белешмәләр туры килү шарты белән, күрсәтелгән гаризаның формасын интерактив формадан файдаланып, электрон рәвештә, нинди дә булса башка формада өстәмә гариза бирү кирәклеге булмаса, тутыралар.

Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле әлеге административ регламентның 9.2 пунктындагы "б" - "з"

пунктчаларында күрсәтелгән беркетелгән электрон документлар белән бергә җибәрә. Гаризага "Электрон имза турында" Федераль законның 8 статьясындагы 5 өлеше нигезендә куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә гади электрон имзадан файдалану кагыйдәләре нигезендә шәхсән кабул иткәндә бирелгән гади электрон имза ачкычын тикшерү ачкычы сертификаты булган очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 25 гыйнварындагы карары белән "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имзадан файдалану турында" 33 номерлы, "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә кулланыла торган электрон имза төрләре турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карарлары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә кулланыла торган электрон имза төрләрен билгеләү кагыйдәләре нигезендә, мондый гаризага кул куярга вәкаләтле мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза яки көчәйтелгән квалификацияләнмәгән электрон имза (алга таба - көчәйтелгән квалификацияләнмәгән электрон имза) белән имза салына, тикшерү ачкычы сертификаты электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада төзелә һәм кулланыла;

б) "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре һәм федераль үзәкләр арасында үзара хезмәттәшлек турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы карары нигезендә төзелгән күпфункцияле үзәк белән җирле үзидарәнең вәкаләтле органы арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә җирле үзидарә органына шәхсән мөрәҗәгать итү юлы белән, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылуы турында хәбәр итеп, почта аша җибәрү.

9.1.2. башка таләпләр, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен, муниципаль хезмәтне экстерриториаль принцип буенча күрсәтү үзенчәлекләрен һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы таләпләр.

Мөрәҗәгать итүчегә яисә аның вәкиленә хезмәт күрсәтү максатларында күпфункцияле үзәкләрдә "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары нигезендә бердәм порталга керү мөмкинлеге тәэмин ителә.

9.1.3. яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турында гаризага мөрәҗәгать итүче тарафыннан теркәлгән электрон рәвештә тапшырыла торган документлар түбәндәге форматларда җибәрелә:

а) xml-XML форматындагы файллар рәвешендә электрон документлар төзү буенча формалар һәм таләпләр расланган документлар өчен;

б) doc, docx, odt-формулаларны үз эченә алмаган текстлы эчтәлекле документлар өчен;

в) pdf, jpg, jpeg, png, bmp, tiff - текстлы эчтәлекле документлар, шул исәптән

формулалар һәм (яки) график сурәтләр, шулай ук график эчтәлекле документлар өчен;

г) zip, rar-бер файлга кысылган документлар өчен;

д) sig-бүтән беркетелгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза өчен.

9.1.4. Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турындагы гаризага беркетелә торган документларның төп нөсхәләре вәкаләтле орган тарафыннан кәгазьдә бирелгән һәм имзаланган очракта, электрон рәвештә тапшырыла торган мондый документларны документның төп нөсхәсеннән 300 - 500 DPI (масштабы 1:1) һәм чынлыкның барлык аутентик билгеләрен (затның график имзасын, мөһерен, бланкның почмак штампын) саклап калып башкарылган турыдан-туры сканерлау юлы белән төзү рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), 300 - 500 dpi (масштабы 1:1) һәм чынлыкның барлык аутентик билгеләре (затның график имзасы, мөһер, бланкның почмак штампы), түбәндәге режимнарны кулланып:

«аклы-каралы» (документта график сурәтләр һәм (яисә) төсле текст булмаганда);

«соры төсмерләре» (документта төсле график сурәттән аерылып торган график сурәтләр булганда);

«төсле» яисә «тулы төстәге» режим» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булганда);

Файллар саны һәрберсе текст һәм (яисә) график мәгълүматны үз эченә алган документлар санына туры килергә тиеш.

9.2 Гариза бирүче тарафыннан яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турындагы гаризага электрон рәвештә тапшырыла торган документлар документны һәм документтагы кәгазьләрнең санын идентификацияләү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге:

а) яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турында гариза. Яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турында гариза әлеге административ регламентның 9.1.1 пунктындагы "а" пунктчасы нигезендә бердәм портал ярдәмендә электрон рәвештә тапшырылган очракта, күрсәтелгән гариза тиешле белешмәләрне бердәм порталда интерактив формага кертү юлы белән тутырыла, башка формада бирү кирәкми;

б) мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (Башкарма комитетка, КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта бирелә). Гариза ЕПГУ ярдәмендә җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең, вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба - ЕСИА) исәп язмасы расланганда күрсәтелгән хисап язмасының тиешле күрсәткечләре составыннан төзелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, гариза җибәрү юлы белән тикшерелергә мөмкин;

в) мөрәҗәгать итүче вәкиленең мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ (мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта). ЕПГУ ярдәмендә мөрәҗәгать иткәндә, оешма тарафыннан бирелгән күрсәтелгән документ оешманың хокуклы вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән, ә физик зат тарафыннан бирелгән документ, беркетелгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза файлы кушымтасы белән, sig форматында нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныклана;

г) агачның үсү урыны тасвирланган дендроплан яисә схема (якындагы адрес ориентирын, шулай ук аны кисү өчен нигезләр турындагы мәгълүматны күрсәтеп);

д) киселергә тиешле җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта), адресы (урнашу урыны), эшләрнең төре, киселергә тиешле яшел утыртмаларның (токымнары, биеклекләре, диаметры һ. б.) характеристикалары күрсәтелгән документ (яшел утыртмаларның исемлек җыелма басмасы);

е) торак яисә торак булмаган урында табигый яктыртуны бозу турында махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе (күзәтчелек органнары күрсәтмәсе булмаган очракта);

ж) яшел үсентеләр үсүгә бәйле төзелеш, санитар һәм башка нормаларны һәм кагыйдәләрне бозу турында махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе (яшел үсентеләр үсүгә бәйле төзелеш, санитар һәм башка нормаларны һәм кагыйдәләрне бозу ачыкланганда);

з) инженер эзләнүләрен башкаруга бирем (инженер-геологик эзләнүләр уздырган очракта.

9.3. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар һәм белешмәләрнең тулы исемлеге.

9.3.1. Вәкаләтле орган тарафыннан дәүләт органнарында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташучы ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып) соратып алына торган хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның (аларның күчермәләренең яисә алардагы белешмәләрнең) тулы исемлеге, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларда, күрсәтелгән документлар үз карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документлар:

а) юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (юридик зат булган мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә);

б) шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (шәхси эшкуар булган мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә);

в) күчемсез мөлкәт объекты турында, күчемсез мөлкәт объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан белешмәләр;

г) күзәтчелек органы күрсәтмәсе;

д) объектны урнаштыруга рөхсәт;

е) җир эшләрен башкару хокукына рөхсәт;

ж) машина йөрү өлешендә яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта, транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте схемасы;

з) төзелешкә рөхсәт.

## 10. Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

10.1. хезмәт күрсәтү турында гариза вәкаләтләренә хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яки оешмага тапшырылу;

10.2. хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру;

10.3. мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчен югалткан булу;

10.4. мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар текстында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартулар һәм төзәтмәләр булу;

10.5. документларда алар булу хезмәт күрсәтү өчен документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар булу;

10.6. гариза формасында кырларны тулысынча тутырмау, шул исәптән ЕПГУда гаризаның интерактив формасында;

10.7. хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон формада билгеләнгән таләпләрне бозып бирү;

10.8. "Электрон имза турында" 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән чынбарлыкны, көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тану шартларын үтәмәү;

10.9. әлеге административ регламентның 9.2 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар әлеге административ регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелә.

Әлеге административ регламентның 9.2 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчегә яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турындагы гаризада мөрәҗәгать итүче билгеләгән ысул белән мондый гариза теркәлгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча җибәрелә яки әлеге карарны алу өчен күпфункцияле үзәккә яки башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Әлеге административ регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту мөрәҗәгать итүченең башкарма комитетка кабат мөрәҗәгать итүенә комачауламый.

## 11. Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

11.1. гаризада һәм аңа кушып бирелгән документларда каршылыклы мәгълүматлар булу;

11.2. мөрәҗәгать итүче тапшырган документлардагы һәм белешмәләрдәге мәгълүматның ведомствоара электрон хезмәттәшлек нәтиҗәсендә алынган белешмәләргә туры килмәве;

11.3. яшел үсентеләрне саклап калу мөмкинлеге ачыклану;

11.4. мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның формасы яисә эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килмәве;

11.5. гариза вәкаләтсез зат тарафыннан бирелү.

Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карар әлеге административ регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелә.

Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчегә яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турындагы гаризада мөрәҗәгать итүче билгеләгән ысул белән мондый карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча җибәрелә яки күрсәтелгән карарны алу өчен күпфункцияле үзәккә яисә башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

## 12. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә

**башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре**

12.1. хезмәт күрсәтү түләүсез башкарыла.

12.2. әлеге административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән яшел үсентеләрне компенсацияләнергә тиешле максатларда кискән очракта, мөрәҗәгать итүчегә яшел үсентеләрне кискән өчен компенсация хакын түләүгә счет куела (әгәр бу Россия Федерациясенең тиешле субъектының җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында каралган булса).

## 13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм вәкаләтле органда яисә күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

13.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм вәкаләтле органда яисә күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмый.

## 14. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризасын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә

14.1 мөрәҗәгать итүченең әлеге административ регламентның 9.1 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турында Арча шәһәре башкарма комитетына тапшырган гаризасын теркәү ул кергән көннең иртәгесеннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

14.2 әлеге административ регламентның 9.1 пунктының "а" пунктчасында күрсәтелгән ысул белән яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турында гариза электрон рәвештә , җирле үзидарәнең вәкаләтле органының эш вакытыннан тыш яисә ял, эш көне булмаган бәйрәм көнендә тапшырылган очракта, яшел үсентеләрне кисү хокукына рөхсәт бирү турында гариза алган көн дип мөрәҗәгать итүче әлеге гаризаны тапшырган көн санала.

## 15. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризалар һәм документлар кабул ителә торган административ биналарның урыны, шулай ук хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре бирелә торган урыннар җәмәгать транспорты тукталышларыннан җәяүлеләр өчен уңайлы булу ягыннан гражданнар өчен уңайлыклар тәэмин ителергә тиеш.

Документларны кабул итү һәм бирү урыны урнашкан бина (төзелеш) янында стоянка (парковкалар) оештыру мөмкинлеге булса, гариза бирүчеләрнең шәхси автомобиль транспорты өчен автомобиль кую урыннары (парковка) оештырыла. Гариза бирүчеләрдән автомобиль кую урыннарыннан (парковкадан) файдаланган өчен түләү алынмый.

Инвалидларның махсус автотранспорт чараларын машина кую урынында (парковкада) кую өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә I, II төркем инвалидлар, шулай ук III төркем инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын һәм шундый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын бушлай кую өчен кимендә 10% урын (ләкин кимендә бер урын) бүлеп бирелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең, шул исәптән инвалид коляскаларында хәрәкәт итүче, бина һәм биналарга керү мөмкинлеген тоткарлыксыз тәэмин итү максатларында, инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларга тоткарлыксыз керү һәм хәрәкәт итү мөмкинлеген бирә торган пандуслар, тотынгычлар, тактиль (контраст) элементлар, башка махсус җайланмалар белән җиһазландырыла.

Вәкаләтле орган бинасына үзәк керү түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати такта (вывеска) белән җиһазландырылырга тиеш:

а) исеме;

б) урнашкан урын һәм адресы, эш режимы;

в)кабул итү графигы;

г) белешмәләр өчен телефон номерлары.

Хезмәт күрсәтү күрсәтелә торган биналар санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормативларга туры килергә тиеш.

Хезмәт күрсәтү күрсәтелә торган биналар түбәндәгеләр белән җиһазландырыла:

а)янгынга каршы система һәм янгын сүндерү чаралары; гадәттән тыш хәл килеп чыгуы турында хәбәр итү системасы; беренче медицина ярдәме күрсәтү чаралары;

б) килүчеләр өчен бәдрәф бүлмәләре.

Мөрәҗәгать итүчеләр өчен көтү залы урындыклар, эскәмияләр белән җиһазландырыла, аларның саны факттагы йөкләнештән һәм аларны бинада урнаштыру мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнә, шулай ук мәгълүмати стендлар белән җиһазландырыла.

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган материал текстлары, ярты майлы шрифт белән иң мөһим урыннарны күрсәтеп, шрифт уку өчен уңайлы итеп бастырыла.

Гаризалар тутыру өчен урыннар урындыклар, өстәлләр (стойкалар), гариза бланкалары, язу әсбаплары белән җиһазландырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары түбәндәге күрсәтмәләр белән мәгълүмати такталар (вывескалар) белән җиһазландырыла:

а) кабинетның номеры һәм бүлекнең исеме;

б) документлар кабул иткән өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булган очракта), вазыйфасы;

в) гариза бирүчеләрне кабул итү графигы.

Документларны кабул итү өчен һәр җаваплы затның эш урыны мәгълүматны кирәкле мәгълүмат базаларына, басма җайланмага (принтерга) һәм күчермә ясаучы җайланмага керү мөмкинлеге булган персональ компьютер белән җиһазландырылырга тиеш.

Документларны кабул итү өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта) һәм вазыйфасы күрсәтелгән өстәл тактасы булырга тиеш.

Инвалидларга хезмәтләр күрсәтелгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) хезмәт күрсәтелә торган объектка (бинага, бүлмәгә) тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге;

б)хезмәт торган биналар һәм бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шулай ук мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

в) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган инвалидларны озатып йөрү;

